**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**Сарман авыл җирлеге**
**423350 Сарман авылы, Ленин ур.,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**

**E - mail: Sar.sar@tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**423350 с. Сарманово, ул.Ленина,52**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @tatar.ru**
ИНН/КПП 16360012661/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 05 октября 2016 года № 9

Сарман авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Сарман авыл җирлеге Уставының 11,12 ст. нигезендә Сарман авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 1 октябрендәге № 11» референдум үткәрү инициативасы турында», Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге Советының 2017 елның 26 сентябрендәге референдум үткәрү инициативасы турында» гы 18 номерлы карары нигезендә, Сарман авыл җирлеге Советы хәл итә:

1.2016 елның 20 ноябренә Сарман авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләнде.

2.Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2017 елда Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән (I һәм II төркем инвалидлар һәм өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшьтән өлкәнрәкләр), җирлек территориясендә ел дәвамында яшәмәүче гражданнар (студентлар, РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар; хөкем ителгәннәр һ. б.) тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (СОП, янгын сүндерүчеләр, авырулар, авырулардан тыш, 350 сум күләмендә үзара салым кертүегез белән килешәсезме һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрәбез:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

2)җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

3) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту);

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

5) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

ЮК, ӘЙЕ.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», PRAVO.TATARSTAN.RU, Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге башлыгы Ф. М. Хөснуллин